**ГЛАВА**
**Исенбаевского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Исәнбай авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ

## КАРАР

13.11.2025 Исәнбай авылы № 2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Гамәлдәге законнар нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге Уставының 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге башлыгы

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2025 елның 29ноябрендә 09 сәг.00 минутына билгеләргә.

2.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2025 елның 29ноябрендә 10 сәг.00 минутка билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүлүне гамәлгә ашырырга:

-1 этап: Исәнбай авылының Совет урамы, Хезмәт урамы, Елга урамы, Ленин урамы.

-2 этап: Исәнбай авылының Мәктәп урамы, Яр буе урамы, Яшьләр урамы, Кирпеч урамы, Октябрь урамы.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

4.1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Федерациясе армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгәннәрне, ирекләрне) һәм аларның гаилә

AnyScanner

әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарны, ир белән хатынны, балигъ булган балаларны) түләүдән азат итеп, 2026 елда үзара салым акчасын 700 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны буенча җирлек өчен әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга ризамы?

**1. Паркны төзекләндерү (волейбол мәйданчыгы урнаштыру)**
**2. Урамнарны яктырту, урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау:**
2.1.Энергияне саклый торган фонарьлар, лампалар һәм урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу һәм аларга алмаштыру, чишмәгә юлны яктырту, электрикка хезмәт килешүе буенча түләү.
**3. Су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:**
3.1 Сантехник материаллар сатып алу һәм җирлекне су белән тәэмин итү (тирәнлек насосларын сатып алу һәм ремонтлау, суүткәргеч челтәрен ремонтлау буенча башка чыгымнар)

**4. Торак пункт территориясен төзекләндерү:**
4.1 Рөхсәт ителмәгән чүплекләрне бетерү өчен дизель ягулыгы, дизель мае һәм трактор запас частьләр сатып алу, карап тоту, аларга хезмәт күрсәтү. Исәнбай авылында газон һәм чүп үләннәрен чаптыру, урамнарны кардан чистарту, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү һәм төзекләндерү буенча башка чыгымнар.
4.2 роторлы чапкыч өчен запас часть сатып алу

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы “Исәнбай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пунктында 2026 елга гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы 2025елның 30октябрендә кабул ителгән 1нче номерлы карарның 1 пунктын (“Үләт базын киртәләү») гражданнар җыены каравына чыгарылган мәсьәләләр арасыннан төшереп калдыруга бәйле рәвештә гамәлдән чыгарырга ризамы?

5. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Исәнбай авылы, Совет урамы, 79 йорт, авыл мәдәният йорты.
6. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

SCAN AnyScanner

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлегенең мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru)

8.Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче Мөхәммәдиев Р.Р.

AnyScanner